**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «НОВОТРОИЦК» АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**«10» август 2022 ел** **№ 23/2**

**«Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Советының 2021 елның 04 декабрь «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар планы чорына Новотроицк авыл җирлегенең бюджеты турында» 15/3 санлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында»**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә һәм «Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Советының 2021 елның 04 декабрь «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар планы чорына Новотроицк авыл җирлегенең бюджеты турында» 15/3 санлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» мәгълүматны тыңлап, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Советының 2021 елның 04 декабрь «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар планы чорына Новотроицк авыл җирлегенең бюджеты турында» 15/3 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә (Новотроицк авыл җирлеге Советының 16.06.2022 ел № 22/1 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып):

- 1 маддә 1 пункт 1 пунктчада «15 355,11» саннарын «19 996,52» саннарына алыштырырга,
- 1 маддә 1 пункт 2 пунктчада «15 482,26» саннарын «21 594,52» саннарына алыштырырга,
- 1 маддә 1 пункт 3 пунктчада «127,15» саннарын «1 598,00» саннарына алыштырырга.

2. Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Советының 2021 елның 04 декабрь «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар планы чорына Новотроицк авыл җирлегенең бюджеты турында» 15/3 санлы карарының 1, 3, 5, 7, 9 кушымталарын яңа редакциядә бәян итәргә.

3. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

5. Әлеге карар халыкка рәсми игълан ителгәннән соң, законлы көченә керә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе Ю.М. Рыбакова